РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЯНУРУСОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ЯНУРЫС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**
20.10.2025 №20

Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының
23.12.2024 №17 карары белән расланган белешмә
(өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 31.07.2025 елгы 304-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясындагы 3 пунктының г, Д пунктчасы нигезендә Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Янурыс авыл җирлеге Башкарма комитетының 23.12.2024 ел, №17 карар белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертергә:

2 бүлек 2.5 пунктының 4 пунктчасында "мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк "сүзләрен" мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк " сүзләренә алмаштырырга.;

2. Әлеге мәгълүматны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Сарман
муниципаль районы Янурыс авыл
җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе А.Ә.Мөхәмәдиева